**Казан шәһәре Думасының**
**2025 елның 14 маендагы 6-38 номерлы карары**

**Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә иҗтимагый-җитештерү объектларын урнаштыру территориаль зонасы (ОП) (27 номерлы контур), иҗтимагый-эшлекле билгеләнештәге объектларны урнаштыру зонасы (ОД) (75 номерлы контур) чикләрен һәм территорияләрдән югары интенсивлыкта файдалану ярдәмче зонасы (ПИИТ), урам-юл челтәре ярдәмче зонасы (УДС) чикләрен үзгәртү өлешендә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең 20, 43, 47 статьялары нигезендә, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 15 декабрендәге 4124 номерлы «Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә иҗтимагый-җитештерү объектларын урнаштыруның территориаль зонасы (ОП), иҗтимагый-эшлекле билгеләнештәге объектларны урнаштыру зонасы (ОД) чикләрен һәм территорияләрдән югары интенсивлыкта файдалану ярдәмче зонасы (ПИИТ), урам-юл челтәре ярдәмче зонасы (УДС) чикләрен үзгәртү өлешендә үзгәрешләр кертү турында Казан шәһәре Думасы карары проектын әзерләү хакында»гы карарын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 30 декабрендәге 905 номерлы «Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең «Урта Кабан күле» территориясен планлаштыру проектын раслау турында»гы карарын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 23 мартындагы 168 номерлы «Җирле әһәмияттәге объектны – Казан зоопаркын реконструкцияләүне, төзүне һәм чикләрен билгеләүне күздә тоткан территорияне планлаштыру проекты раслау турында»гы карарын һәм 2025 елның 16 гыйнварыннан 2025 елның 30 гыйнварына кадәр үткәрелгән иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләрен исәпкә алып, Казан шәһәре Думасы **карар бирде:**

1. Казан шәһәре Думасының 2021 елның 16 августындагы 5-8 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә (алга таба – Кагыйдәләр) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. шәһәр төзелешен зоналаштыру (территориаль зоналар) картасында территориаль зона – иҗтимагый-җитештерү объектларын урнаштыру зонасы (ОП) (27 номерлы контур) чикләренә әлеге карарга 1 номерлы кушымта нигезендә территорияне кертеп, территориаль зона – иҗтимагый-эшлекле билгеләнештәге объектларны (ОД) (75 номерлы контур) урнаштыру зонасы чикләрен үзгәртергә;

1.2. территориаль зоналарның ярдәмче зоналары: урам-юл челтәре, табигать-рекреация комплексы, махсус билгеләнештәге яшелләндерү, яр буе территорияләре күрсәтелгән шәһәр төзелешен зоналаштыру картасында, территориягә карата әлеге карарның 2 номерлы кушымтасы нигезендә, урам-юл челтәре (УДС) ярдәмче зонасы чикләрен үзгәртергә.

1.3. территориаль зоналарның территориядән югары интенсивлыкта файдалану, шәһәр төзелеше әһәмиятендәге территорияләр ярдәмче зоналары күрсәтелгән шәһәр төзелешен зоналаштыру картасында әлеге карарга 3 номерлы кушымта нигезендә территориаль зона – иҗтимагый-эшлекле билгеләнештәге объектларны (ОД) (75 номерлы контур) урнаштыру зонасы чикләрен үзгәртергә;

1.4. әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән территориаль зоналарның үзгәрә торган чикләрен Кагыйдәләр составында шәһәр төзелешен зоналаштыруның түбәндәге карталарында чагылдырырга:

- шәһәр төзелешен зоналаштыру (территориаль зоналар) картасы;

- территориаль зоналарның урам-юл челтәре, табигать-рекреация комплексы, махсус билгеләнештәге яшелләндерү, яр буе территорияләре ярдәмче зоналары күрсәтелгән шәһәр төзелешен зоналаштыру картасында;

- территориаль зоналарның территорияне югары интенсивлыкта файдалану, шәһәр төзелешендә әһәмияткә ия территорияләр ярдәмче зоналары күрсәтелгән шәһәр төзелешен зоналаштыру картасында;

- территориаль зоналарның ярдәмче зоналары: тарихи җирлек ярдәмче зонасы күрсәтелгән шәһәр төзелешен зоналаштыру картасында;

- чикләрендә территорияләрне комплекслы үстерүне гамәлгә ашыру күздә тотыла торган территорияләр картасы;

1.5. Кагыйдәләргә 1 номерлы кушымтаны әлеге карарга 4 номерлы кушымта (хезмәт урынында файдалану өчен) (китерелми) нигезендә

территориаль зоналар чикләре урнашу урынының график тасвирламасы белән тулыландырырга;


1.6. Кагыйдәләргә 2 номерлы кушымтаны әлеге карарга 5 номерлы кушымта (хезмәт урынында файдалану өчен) (китерелми) нигезендә территориаль зоналар чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга.

**Шәһәр Мэры** **И.Р.Метшин**

Казан шәһәре Думасының
2025 елның 14 маендагы
6-38 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре составында шәһәр төзелешен зоналаштыру (территориаль зоналар) картасы фрагменты**




**Шартлы билгеләр:**

**ОП - 27**

Территориаль зона контурының тәртип номеры

Территориаль зона индексы


**Территориаль зона**

| **Төс** | **Индекс** | **Территориаль зона төренең атамасы** |
|---|---|---|
| | ОП | Иҗтимагый-җитештерү объектларын урнаштыру зонасы |
| | | Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре составында шәһәр төзелешен зоналаштыру (территориаль зоналар) картасы фрагменты чикләре |

**Башлыкның беренче урынбасары** **Д.Г.Калинкин**

Казан шәһәре Думасының
2025 елның 14 маендагы
6-38 номерлы карарына
2 номерлы кушымта

# Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре составындагы территориаль зоналарның урам-юл челтәре, табигать-рекреация комплексы, махсус билгеләнештәге яшелләндерү, яр буе территорияләре ярдәмче зоналары күрсәтелгән шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы фрагменты




**Шартлы билгеләр:**

**ОД - 75**

Территориаль зона контурының тәртип номеры

Территориаль зона индексы

**Территориаль зона**

| Төс | Индекс | Территориаль зона төренең атамасы |
|---|---|---|
| | ОД | Иҗтимагый-эшлекле билгеләнештәге объектларны урнаштыру зонасы |
| | ОП | Иҗтимагый-җитештерү объектларын урнаштыру зонасы |
| | С1 | Зиратларны урнаштыру зонасы |
| | ОЖ | Катнаш торак һәм иҗтимагый төзелеш зонасы |
| | Р0 | Махсус табигатьне саклау, рекреация һәм башка кыйммәтле әһәмияткә ия зона |
| | Р2 | Рекреация зонасы |
| | Т | Транспорт объектларын урнаштыру зонасы |
| | Р3 | Иҗтимагый функцияләр өлеше булган рекреация зонасы |


**Территориаль зоналарның ярдәмче зоналары**

| Төс | Индекс | Территориаль зонаның ярдәмче зонасы төре атамасы |
|---|---|---|
| | УДС | Урам-юл челтәре ярдәмче зонасы |
| | | Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре составында территориаль зоналарның ярдәмче зоналары: урам-юл челтәре, табигать-рекреация комплексы, махсус билгеләнештәге яшелләндерү, яр буе территорияләре күрсәтелгән шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы фрагменты чиге |

**Башлыкның беренче урынбасары** **Д.Г.Калинкин**

Казан шәһәре Думасының
2025 елның 14 маендагы
6-38 номерлы карарына
3 номерлы кушымта

**Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре составындагы территориаль зоналарның территорияне югары интенсивлыкта файдалану, шәһәр төзелеше ягыннан әһәмияткә ия территорияләр ярдәмче зоналары күрсәтелгән шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы фрагменты**




**Шартлы билгеләр:**

**ОД - 75**

Территориаль зона контурының тәртип номеры

Территориаль зона индексы

**Территориаль зона**

| Төс | Индекс | Территориаль зона төренең атамасы |
|---|---|---|
| | ОД | Иҗтимагый-эшлекле билгеләнештәге объектларны урнаштыру зонасы |
| | ОП | Иҗтимагый-җитештерү объектларын урнаштыру зонасы |

**Территориаль зоналарның ярдәмче зоналары**

| Төс | Индекс | Территориаль зонаның ярдәмче зонасы төре атамасы |
|---|---|---|
| | ПИИТ | Территорияне югары интенсивлыкта файдалану ярдәмче зонасы |
| | | Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре составындагы территориаль зоналарның территорияне югары интенсивлыкта файдалану, шәһәр төзелеше ягыннан әһәмияткә ия территорияләр ярдәмче зоналары күрсәтелгән шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы фрагментының чиге |

**Башлыкның беренче урынбасары** **Д.Г.Калинкин**